# Нәсыйхәт

җомга
27
гыйнвар
2012 №12

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## Яңалыклар

### “ИҢ ЯХШЫ ДИНИ МӘКАЛӘ” БӘЙГЕСЕ

Мамадыш мәдрәсәсе “Иң яхшы дини мәкалә” бәйгесен үткәрүне дәвам итә. Ул 1нче гыйнвардан алып 30нчы февральга кадәр дәвам итәчәк. Редакциягә җибәрелгән һәрбер мәкалә “Нәсыйхәт” гәҗитендә басылачак. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә.

### ПӘЙГАМБӘРЕБЕЗГӘ (С. Г. В.) БАГЫШЛАП

Мамадыш мәдрәсәсе Пәйгамбәребезгә (с. г. в.) багышланган шигырь бәйгесе игълан итә. Конкурс бер ай дәвамында, төгәлрәк әйткәндә, 1нче февральдан алып 28нче февральгә кадәр дәвам итәчәк. Җиңүчеләрнең әсәрләре “Нәсыйхәт” гәҗитендә басылачак. Аларны истәлекле бүләкләр көтә.

### ОЛЫЯЗ МӘЧЕТЕНДӘ ҖЫЕН

Район мөхтәсибе Илһам хәзрәт һәм мәдрәсә директоры Габдрахман хәзрәт район авылларына эшлекле сәфәр белән йөрүләрен дәвам итәләр. 24нче гыйнвар көнне алар Олыяз авылында узган җыенда катнаштылар. Ислам диненә кагылышлы вәгазь сөйләделәр, дини гыйлемнең әһәмиятлеге турында сүз алып бардылар. Мамадыш мәдрәсәсенә укырга чакырдылар.

## ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

### Хәләл һава аланнары арта

Малайзиядәге Куала-Лумпур, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренең Дубай, Төркиянең Истанбул шәһәрендәге Ататөрк исемендәге халыкара һава аланнары мөселманнар өчен иң кулай дип табылган.
Мөселман туристлар елдан-ел арта бара. Нәкъ шуны исәптә тотып дөньядагы күп кенә һава аланнары мөселманнарга капкалап алырга да, намаз укырга һәм башка уңайлыклар да булдырырга тырыша. Crescentrating ширкәте Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кергән илләрдәге һәм бу оешма әгъзасы булмаган дәүләтләрдәге мөселманнарга кулайлыклар тудырылган 20 иң яхшы һава аланын барлады.
Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кергән илләрнең һава аланнарында хәләл ризык белән туклану урыннары, намаз уку өчен махсус бүлмәләр дә күбрәк, дип белдерә Crescentrating. Бу оешма илләрендәге һава аланнарында хаҗилар өчен махсус терминаллар булдырылган.
Ислам хезмәттәшлеге оешмасына кермәгән илләрдәге һава аланнарында да мөселманнарга кулайлыклар тудыру елдан-ел арта бара. Кайбер һава аланнары төрле диндәгеләр кереп гыйбадәт кыла алсын өчен уртак бүлмәләр булдыра. Хәләл ризык табу да җиңелләшә бара.

### «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» бәйгесе узачак

6 апрельдә Казандагы «Мәрҗани» мәчетендә балалар һәм яшүсмерләр өчен «Сөембикә энеләре һәм сеңелләре» дигән Бөтенроссия конкурсы үтәчәк. Бәйгене оештыручы «Мөслимә» иҗтимагый оешмасы рәисе Әлмира апа Әдиатуллина сүзләренчә, конкурста катнашучылар Коръән һәм ислам нигезләрен белү буенча ярышачак.
Әлеге бәйгене үткәрү күркәм гадәткә әйләнде. Быел ул 15 нче тапкыр уздырыла. Анда 4тән 18 яшькәчә балалар катнашачак.

## Изге Коръән елы



# Коръән ятлыйм дисәң...

**Мәдрәсәгә йөрүче һәр кешенең, гомумән алганда һәр мөселманның иң изге хыялы әлбәттә Коръән ятлау буладыр. Коръән укуның, аны яттан белүнең фазыйләтләре, саваплары санап бетергесез. Танылган гарәп Коръән хафизы (Коръәнне яттан белүче) Мишари Рашид безгә нинди киңәшләр бирә соң?**

1. Аллаһ ризалыгы өчен ятлау.
Кайбер вакытта кардәшләребезнең гамәлләрен күргәзмә өчен башкарганнарын күрәбез. Динебездә исә ихласлык, эшне Аллаһ ризалыгы өчен башкару беренче урында тора. Шул исәптән имам Мөслим һәм Бухари да үзләренең хәдис җыентыкларын ният хакындагы хәдисләр белән башлаганнар.
2. Максат билгеләү.
Мәсәлән: “Мин тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнгәч, бер җүз Коръән ятлаячакмын һәм бар тырышлыгымны куячакмын.
3. Һәрдаим Коръән ятлауга вакыт билгеләү һәм әлеге графиктан тайпылмау.
“Иң хәерле эш – дәвамлы эш” дигән гыйбәрәне истән чыгармау мөһим.
4. Шөгыльләнергә иң кулай булган вакытны һәм урынны сайлау.
Әгәр дә сезгә өйдә укырга балалар комачаулый икән, димәк сезгә мәчеткә барып өйрәнергә кулайрак булыр.
5. Өйрәнер өчен билгеле бер Коръән сайлау.
Авторның бу хакта әйтүе очраклы түгел, чөнки кешенең күз хәтер сәләте бар. Димәк, Коръәннең билгеле бер төр шрифтына күнеккәч, аны алыштыру киңәш ителми.
6. Авырлыклардан курыкмау.
Гадәттә башлап җибәрүчеләр начар хәтер яисә хәрефләрнең авыр әйтелеше белән бәйле булган мәсьәләләргә юлыгалар. Әлбәттә, бу вакытлыча күренеш. Ләкин, кайбер мөселманнар шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, дәресләрен ташлыйлар. Алардан төрле сәбәпләр ишетергә туры килә: ”Мин мәктәптә начар укыдым, миннән булмас инде” яисә “Мин картайдым, зиһенем дә юк”.

**(Дәвамы 2нче биттә)**

# МАВЫКТЫРГЫЧ ҺӘМ ФАЙДАЛЫ ҖИДЕ КӨН



**Гыйнвар аеның беренче декадасында, кышкы каникул көннәрендә, Мамадыш мәдрәсәсе базасында балалар лагере оештырылды.**

Җиде көн дәверендә төрле авыллардан килгән 25ләп бала мәдрәсәдә укыдылар һәм файдалы ял иттеләр. Әти-әниләр балалары өчен борчылмадылар, чөнки тәрбияле, ачык йөзле, киң күңелле, һәр кешене ихтирам итә белә торган мөгаллимнәр һәм тәрбиячеләр күзәтүе астында булдылар. Мәдрәсә укытучыларының чыгышлары балалар күңеленә тирән үтеп керерлек иде. Өлкәннәргә хөрмәт, әти-әнигә булган бурычлар турында сөйләделәр. Мәктәптә тырышып укырга кирәклеген, хәзерге заман яшьләре өчен белемсезлекнең никадәр авыр икәнлеген дини әхлак белән бәйләп өйрәттеләр. Лагерь ислам диненең әхлак нормаларына туры килүче таләпчән кагыйдәләргә нигезләнеп оештырылды. Барлык тәрбияләнүчеләр дә бишвакыт намаз укыдылар. Аларга ял итү, яхшы туклану өчен барлык шартлар да тудырылды. Балалар вакытлыча гына булса да, туган өйләреннән аерылып бирегә килгәннәр. Алар әти-әниләрен, туганнарын бик сагыналар. Моны да онытмадылар тәрбиячеләр. Спорт ярышлары уздырып, ислам кинолары күрсәтеп, призлар биреп, кучтәнәчләр белән сыйлап, балаларның күңелләрен күтәреп тордылар. Күңел ачу чараларыннан тыш, аларга Коръәнне дөрес итеп уку дәресләре, дога кылу рәвешләре күрсәтелде, тәфсилләп аңлатылды. Азан конкурсы бик күңелле узды. Араларыннан башта җиңүчеләрне аерып алу да мөмкин булмады, чөнки һәммәсенең дә азаны матур килеп чыкты. Җиңүчеләрне билгеләү өчен өстәмә сораулар бирергә туры килде. Аңа хәтта олылар да тиз генә җавап бирә алмас иде. Малайлар изге йортта үзләрен уңай яктан күрсәттеләр, үзләренә хас булганча, шаярып та алдылар. Бигрәк тә алар бүләк ителгән китапларга, бүләкләргә куандылар. Тауда чаңгы-чанада шудылар, башка төрле күңел ачу чараларында катнаштылар. Мәдрәсәдәге җиде көн бик тиз узып китте, калган вакытларын өйдә үткәрделәр. Димәк, аларның каникулы ике өлешкә бүленде, яллары ике тапкырга арткандай тоелды. Шуны әйтеп үтәргә кирәк, мондый лагерьларда балалар урамның тискәре йогынтысыннан арыналар, рәхәтләнеп ял итәләр, сәламәтлекләрен ныгыталар, дини белемнәр һәм тәрбия алалар, тәртипкә, олыларны хөрмәт итәргә өйрәнәләр. Алар арасында дус мөнәсәбәт һәм бер-беренә мәрхәмәтлелек хисе урнаша. Бу балаларның алдагы тормышларын күзәтсәк, аларның күбесе нык позициядә тора, прогрессив фикер йөртә һәм дини белемнәрен югары уку йортларында дәвам итә. Җәмгыять инде мондый лагерьларның кирәклеген төшенде. Димәк, киләчәктә аларның күбәюе перспективада тора.

# Коръән ятлыйм дисәң...

7. Коръәнне үзлектән үзләштерәсез икән, дөресләгән белүче кешедән тикшертегез.

8. Коръәнне укыган вакытта, кычкырып укырга тырышыгыз.

Башта бер аятьне өйрәнегез, аннан икенчесен ятлагыз, аннан соң икесен бергә кушыгыз. Шул рәвешле дәвам итегез. Тәһарәтле булыгыз. Укыган вакытта төз утырыгыз, сезнең утырышыгыз җитди укуга ишарә итсен – бу әдәп мәсьәләсенә кагыла.

9. Ятлаган аятьләрегезне туганнар, дуслар каршында укып күрсәтегез –булган кимчелекләр ачыкланыр, үз-үзегезгә ышанычыгыз артыр, вакытыгызны саваплы гамәл белән үткәрерсез.

10. Өйрәнгән сүрәләрегезне кабатлап торырга тырышыгыз, бигрәк тә намаз укыганда кулланыгыз.

11. Аллаһы Тәгалә белемнәрегезне дәвамлы, зиһенегезне зирәк кылсын өчен, гөнаһлардан сакланыгыз, гайбәтне калдырыгыз.

12. Мөмкин кадәр күбрәк Коръән уку түгәрәкләренә йөрегез. Җәмәгать намазларыннан соң да, бергәләп мәчеттә калып Коръән уку бик файдалы булыр.

13. Гыйлем эстәүче үзенең ашавына да игътибар итәргә тиеш: чамадан артык ашау зиһенне чуалта һәм шаһвәткә тарта.

14. Инде ниһаять, беренче нәтиҗәләргә ирешкәннән соң, тәкәбберлек чиренә бирешә күрмәгез. Үзегез белән горурланмагыз. Хәдистә килә: "Кешене өч нәрсә һәлакәткә илтә: шуның берсе –үз-үзеңне артык ярату".

15. Аллаһтан гыйлем сорап һәрдаим дога кылыгыз.

Коръәнне яттан белүче Мишари Рашидиең тәкъдим һәм нәсыйхәтләре сезгә ярдәм итсен.

**ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА ӘЗЕРЛӘДЕ.**

**Сезнең иң хәерлегез–кем Коръәнне өйрәнде һәм башкаларга өйрәтте.**

# БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ НИГЕЗЛӘРЕ

**Никах килешүенең нигезендә мөселман ир белән хатын-кызның бердәмлеге ята. Ләкин кайбер яңа парлар гаилә мөнәсәбәтләрен ахырга кадәр аңлап бетерә алмыйлар. Аннары катлаулы хәлләр барлыкка килә. Шуңа күрә, ислам дине буенча никах – хатын-кыз белән ир-ат арасында изге һәм хокукый килешү. Алар икесе дә барлык мөнәсәбәтләр буенча да Аллаһ һәм бер-берсе каршындагы бурычларын аңлап үтәргә тиешләр. Хатын-кыз ирнең дусты һәм ярдәмчесе була, алар икесе дә гаилә эшләре һәм балалары өчен җаваплы.**



Гаилә — ул чиксез диңгез кебек. Анда адашмас өчен, кулыңда гыйлем компасы булырга тиеш. Проблема, гадәттә вак-төякләрдән чыга. Шуларны чишәргә әзер булырга кирәк.

Коръән Кәримдә һәм Пәйгамбәребез (с.г.в) хәдисләрендә гаилә мәсьәләләре инәсеннән җебенә кадәр язылган. Укы да, файдалан гына! Гомумән, Пәйгамбәребез (с.г.в.)нең гаиләсенә мөнәсәбәте безнең өчен югары үрнәк. Ир белән хатын мөнәсәбәтләре турында нәрсә генә язмасыннар, нинди психологик китаплар чыгармасыннар — болар барысы Изге Китабыбызда язылганнардан яхшы була алмый.

Совет власте елларында татар халкының гаилә нигезләре какшады. Моның сәбәбе халыкның диннән ераклашуы, гаиләләрне шәригатькә муафыйк рәвештә алып бармау иде. Нәтиҗәсе буларак балалар һәм яшүсмерләр җинаяте килеп чыкты. Чөнки эшләүче аналарның балаларын яхшылап тәрбияләү өчен вакыты һәм мөмкинлеге калмады. Моннан тыш, хатын-кызның тормыш өчен кирәкле акчаны үз көче белән табуы ирләрнең эшләү теләген киметтe һәм билгеле бер дәрәҗәдә аларның соры корт булып кеше җилкәсендә яшәвенә һәм әзүчелеккә китерде.

Шәригать буенча гаиләдә ир баш. Хатын-кыз ике очракта гына: ире сәләтсез яки каты авырганда гына суд аша аеруны таләп итә ала. Татар халкы шул таләпне үтәгән, ә ул исә тату яшәүгә һәм татарлар арасында аерылышуның юк дәрәҗәсендә аз булуына китергән. П. Знаменский болай яза: “... татар гаиләсе берәр җиргә йөрергә яки барырга чыкса, ир кеше гел алда була, ә аның артыннан балаларын ияртеән татар хатыны бара, ул аның белән тигезләнергә хаксыз, ирен узып алга чыгуы турында әйтәсе дә юк”. “Шуңа күрә аның бөтен уй-нияте ирен мәхәббәте белән тотып торуга, кершән, иннек, матур киемнәр белән кызыктыруга, аның табигый теләкләрен үтәүгә һ. б. юнәлгән”. Алда зекер ителгәннәр шуны исбатлый: ислам динендә гаиләдә ир-ат хуҗа, чөнки ул физик яктан да, психик яктан да хатын-кыздан көчлерәк була. Шул сәбәпле, гаиләне тәэмин итү вазыйфасы ир-атка йөкләтелгән. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Ирләр хатынга әдәп, тәрбия бирмәк өчен каимнәрдер (өстеннәрдер). Аллаһ мәхлукләрне кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр гакылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга инфак кылу белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстендер. Изге хатыннар Аллаһыга һәм ирләренә итәгать итәрләр, ирләре өйдә булмаганда Аллаһ саклавы белән малларын һәм үзләрен саклarлар, һичбер хыянәткә бармаслар... Әгәр хатыннарыгыз сезгә итагать итсәләр яки явызлыкларыннан соң төзәлсәләр, алар зарарына юл эзләмәгез, ягъни хаксыз җәберләмәгез. Әлбәттә, Аллаһ бөек һәм олы булды» (4:34).

Хәзерге вакытта күп кеше ислам динен тотучы хатын-кызны кухнядан беркая да китмәүче иренең колы дип тә уйлый. Моның хакында Америка һәм Европа газеталарында күпертеп язылган.

Шуларга җавап итеп, шуны әйтергә кирәк: ислам динендә ир-ат белән хатын-кызның хокуклары тигез. Бу аларның Аллаһ каршында тигез булулары белән аңлатыла.

Ислам дине икесенә дә бер үк фарыз гамәлләрне үтәргә кушты, тик хатын-кызларга бала туу белән бәйле булган җиңеллекләр дә бар. Изге гамәлләр, гыйлем алу ир-атларга да, хатын-кызларга да тиеш булды. Аллаһы Тәгалә әйтә: «Берәү чын мөэмин хәлендә изге гамәлләр кылса, кирәк – ир булсын, кирәк – хатын булсын, алар җәннәткә керерләр һәм җеп очы хәтле дә золым кылынмаслар» (4:124).

Ислам дине күзлегеннән күренгәнчә, хатын-кызлар ир-атлардан чагырштырмалы буларак, хискә бик бирелүчән булалар, шуңа күрә хатын-кызларга карата яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәк. Моның хакында Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) күп кенә хәдисләрендә бирелгән. Ул болай ди: «Ирләрнең иң яхшылары хатыннарына карата яхшы мөнәсәбәттә булучылар». Ир-ат белән хатын-кызның табигатьләре бер үк булмагач, икесенә ике төрле вазыйфа йөкләтелде. Алар бер-берсен тулыландырып торалар, ә ул җәмгыятьнең үсеше өчен кирәк. Иҗтимагый тормышка икесе дә үз өлешен кертергә хокуклы. Хатын-кыз җәмгыятьтә төрле эшләр башкара ала, мәсәлән, тыйбб, иҗтимагый эшләр, белем бирү һ.б. Пәйгамбәребез (с.г.в.) вакытында алар Мөхәммәд (с.г.в.) белән төрле мәсьәләләрне хәл иттеләр, ә кайвакытта бәхәсләштеләр дә. Күп кенә мөселман галимнәре теге яки бу сорау буенча Гайшә, аннан Раббыбыз разый булсын, янына килеп киңәшләшәләр иде. Апасы Әсма гомере буе зур батырлыклар күрсәтте.

Коръәндә ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр хакында да әйтелгән:

«Дәхи Аллаһының кодрәтенә дәлилләрдәндер сезнең өчен Аллаһының үзегездән хатыннар яратмаклыгы, чөнки Һава Адәмнең кабыргасыннан халык ителде, ул хатыннар белән өлфәтләнеп бергә яшәвегез өчен, дәхи ир белән хатын арасында дуслык һәм мәрхәмәтлек кылды, әлбәттә, Аллаһының бу эшләрендә фикерли белгән кешеләр өчен гыйбрәт бардыр» (30:21).

Хатын-кызлар күбрәк өйдә эшләгәч, ислам дине тыштагы эшләрне эшләргә мәҗбүр итми. Ир кеше өй эшләрендә дә хатынына булышырга тиеш.

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН әзерләде.**

**(Дәвамы киләсе санда)**

## Сорау–җавап

**–Мин инде өченче елымны намаз укыйм. 2-3 минут эчендә 1 генә тапкыр тәһарәт алган кешеләргә көнләшеп карыйм. Ә миңа якынча 5-6 мәртәбә алырга туры килә тәһарәтне. Әйтик, кулларны юганда, авызны чайкамаганлыгым искә төшә һәм тәһарәт алуны яңадан башларга кирәк була. Намазны да мин тыныч кына укый алмыйм. Сүзләрне дөрес әйттемме икән дип шикләнгәнгә, догаларны күп тапкырлар кабатларга туры килә. Намаз укыганда төрле тавыш мине чыгырдан чыгара, абсолют тыныч урынны табасы була. Минем белəсем килә: мондый мәсьәләсе булган кешеләр бармы икән? Кайберәүләр бу хәлне үз-үзеңне ышандыру гына дип атыйлар. Үз-үзеңне ышандыру 2 елдан артык дәвам итә аламы?**

**ЭЛИЗА**

–Кызганыч Сезнең мондый хәлегезнең инде өченче ел дәвам итүе. Сезнең белән булган әлеге хәл әйбәт түгел. Мөселманнар илаһияте белемендә борынгы заманнардан бирле шулай булып тоелган нәрсәләргә игътибар бирмәскә кушыла. Ничек кенә булып тоелса да, тәһарәтне бер генә тапкыр алыгыз. Намазны да киеренке рәвештә укымагыз, бүлдерергә теләгән нәрсәләргә әһәмият бирмәгез. Кан әйләнешен яхшырту өчен күбрәк физик күнегүләр эшләгез, актив тормыш рәвеше алып барыгыз. Хәләл ризыклар кулланыгыз, дөрес ял итү, вакытында йоклау һәм йокыдан тору шулай ук зур әһәмияткә ия. Үзегезне ныклы режимда тотыгыз һәм шулай дәвам итегез.

**–Бездә, Россиядә ислам банклары бармы? Шәригать кысаларыннан чыкмыйча, машинаны ничек сатып алырга?**

**РИНАТ**

–Россиядә хәзерге вакытта ислам банклары юк. Шулай ук мин сезгә кредитка машина алырга киңәш итмим. Сабыр итегез, 1 ел яхшылап эшләгез, кирәкле сумманы җыегыз, ә җитмәгән акчаны туганнарыгыздан, якыннарыгыздан әҗәткә алып торыгыз. Бурычка алу турында кәгазь языгыз һәм аны үзвакытында түләп барыгыз. Соңгы 20 елдагы тормыш тәҗрибәмнән чыгып шуны әйтә алам: хәтта зур күләмдә акча алып торган кешеләр дә әҗәтләрен кире кайтарырга оныталар. Ә бурычны кире кайтармау–зур гөнаһ.

**–Әйтегез әле: сырны кулланырга ярыймы? Моны шуңа күрә сорыйм: аны әзерләгәндә пепсин дигән порошок кушалар. Ә бу порошок хәләл булмаган хайванның ашказаныннан алына. Ә кайбер сырларны хәтта дуңгыз ашказанында тоталар.**

**АНЖЕЛИКА**

–Сырның составына игътибар итегез. Ашказаны согы ферменты (сычужный фермент) кушып эшләнмәгән сырларны кулланыгыз.

**Бу сорауларга җаваплар umma.ru сайтыннан алып тәрҗемә ителде.**

## БЕЛДЕРҮЛӘР

Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485

Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мәрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391

Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь-мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

Мәдрәсә базасында Ислам диненә караган сорауларга җавап бирү хезмәте

Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

Мәдрәсә "Бер айда намаз укырга өйрән" түгәрәгенә укучылар җыя, Белешмәләр өчен телефон: 89172802391

## Шигъри дулкында

### Барлыгыңны таныйм

Дөньядагы һәрбер
могҗизаны
Нигә табигать дип
алдадың?
Бар нәрсәдән
Аллаһ бөеклеген,
Үсеп җиткәч кенә
аңладым.
Бары синең ярдәм
белән генә
Сулый алам дөнья
һавасын.
Ярлыкавың,
юмартлыгың өчен,
Рәхмәт сиңа,
Бөек Аллаһым.

### Иманың нык синең

Зур тәрәзле
агач мәдрәсәдә
Абыстайдан белем
алганнар.
–Аллаһ юк,–дип
имансызлар
Балта белән чабып,
Манарасын җиргә
салганнар.
Мәчетенә тиеп
мөселманның,
Күңеленә яра салганнар.
Көчле рухлы, сабыр,
ихтыярлы
Иманына чаба алмаганнар.

### Язлар көтәм

Кыш җитүгә,
бар тереклек көтә
Җылы, ямьле
язлар җиткәнен.
Ашыктырып
килер вакытларны,
Сизмибез лә
гомер үткәнен.
Озын кышның
тирән карларыннан,
Көчкә-көчкә җирләр
арчыла.
Ямансулап карап
калам һәрчак
Бозны алып киткән ташуга.
Кар астыннан
чыккан саргылт үлән
Хәтерләтә иске келәмне.
Күңелемдә яшәү
дәрте туа, күргәч
Яңа туган яшел үләнне.
Шифа алып
саф һавасын сулыйм,
Язлар җиткәч
күңелем яшәрә.
Үзеңнән соң якты
эз калдырып
Яшәү өчен – кирәк яшәргә.

**ӘЛФИРӘ ХАҖИЕВА**

### Иманлы бул!

Иң әвәле күңелеңә,
Салып куй,
АЛЛАҺ барын.
Шик-шөбһәләр китермичә,
Тик син аңарга табын.
Изге эшләреңне эшлә,
Күңелеңнең түреннән,
Начар уйны, көнләшүне–
Онып аны бүгеннән.
Уйла! Гомер бер генә ул,
Хөрмә кебек бер кисәк.
Уең яхшы булу кирәк,
Иманлы булыйм, дисәң!
.................................

**ГӨЛНУР ВАСЫЙЛОВА**

***

Дөнья нурсызланды,
Җаннар сызланалар,
Яшәештә аһ-зар,
сагышлар,
Җылы якты хисләр
Чәбәләнеп тынды,
Упкыннарга илтә ялгышлар.
Зәңгәр күк тә бездән
Читләшкәндәй тоела,
Җылы җитми җанга,
нур җитми,
һәр көн саен арта
Магнит давыллары,
Әллә кояштагын үз итми?
Чирле табигать тә,
Чирле кешеләр дә,
Ак өметләр сүнеп югалды...
Ни өчен соң, Тәңрем,
Безнең язмышларга,
Суык кара томан уралды?
Кара шомлы томан
Җанны күшектерде,
Гөнаһ упкынында җиребез,
Керсез караш белән
Чор күзенә карап,
Яши алыр микән Илебез?

**СӘЯФ ШӘЙХИ**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 100 данә.**